КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 598

«Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 июль, 598 нче
карары белән расланды

**«Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Коррупциягә каршы бизнес иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (алга таба – Үзәк, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет чараларын алучы буларак Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия Үзәк эшчәнлегенең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

4. Үзәкнең финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр булып тора:

хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү һәм аларны матди бүләкләү;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

коммуналь хезмәтләр, бүлмәләрне, җайланманы, җиһазларны арендалау өчен түләү;

транспорт һәм элемтә хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү;

оештыру техникасы, шәхси компьютерлар, сервер һәм челтәр җиһазлары сатып алу һәм карап тоту;

программа белән һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү;

чыгым материаллары сатып алу;

уставтагы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

5. Әгәр дә Үзәк субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның бересенә түбәндәге таләпләргә туры килсә, субсидия аңа бирелә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаса;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаса;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында тормаса;

башка норматив хокук актлары нигезендә бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаса.

6. Субсидия алу өчен Үзәк Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслый торган форма буенча субсидия алуга гариза (алга таба – гариза);

Үзәкнең билгеләнгән тәртиптә таныкланган гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

Үзәкнең бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләре буенча чыгымнар сметасын;

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның бересенә түбәндәгеләрне раслый торган документларны:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмавын;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавын;

Үзәкнең үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында булмавы һәм башка норматив хокук актлары нигезендә бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавы турында һәм Үзәк җитәкчесенең имзасы куелган белешмә кәгазен.

7. Бирелә торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен Үзәк Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Министрлык:

Үзәкнең гаризасын кергән көнендә үк документлар әйләнеше кагыйдәләре нигезендә терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә тапшырылган документларны Үзәккә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кире кайтара.

9. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Үзәк тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 6 нчы пунктында куелган таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

Үзәк тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

10. Субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

11. Субсидияләр бирү Министрлык һәм Үзәк арасында төзелгән килешү нигезендә башкарыла. Килешү субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән расланган бертип форма нигезендә төзелә.

12. Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм вакытлары, субсидиядән файдалану турындагы хисапларны тапшыру вакытлары һәм формалары, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылу очраклары, Министрлык тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен файдалануда ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, алар финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, субсидия алучының Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәүгә карата тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы, югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, Үзәкнең бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турындагы нигезләмә карала.

13. Субсидия Министрлык тарафыннан субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә Үзәкнең Россия кредит оешмасында ачылган хисап исәбенә күчерелә.

14. Үзәк Министрлыкка субсидияне файдалану турындагы хисапны килешүдә билгеләнә торган форма буенча һәм вакытларда кертә.

15. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы законнар нигезендә бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә мәҗбүри тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

16. Бирелгән субсидия, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары нигезендә Үзәк тарафыннан субсидия бирүнең бу Тәртип белән билгеләнгән шартларының үтәлмәве ачыкланган очракта, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 30 көн эчендә бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

17. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, килешүдә каралган очракларда, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты keremenә кире кайтарылырга тиеш.

18. Субсидия алучылар бу Тәртипнең 16 нчы һәм 17 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару вакытларын бозганда, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.